| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының иң яхшы дәүләт граждан хезмәткәре» республика конкурсы турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасының иң яхшы дәүләт граждан хезмәткәре» республика конкурсын оештыру һәм уздыру тәртибен камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының иң яхшы дәүләт граждан хезмәткәре» республика конкурсы турында» 2014 елның 16 маендагы ПУ-479 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 27 июнендәге ПУ-604 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы һәм 2021 елның 27 февралендәге ПУ-188 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Татарстан Республикасының иң яхшы дәүләт граждан хезмәткәре» республика конкурсын кимендә ике елга бер тапкыр үткәрергә.»;

б) «Татарстан Республикасының иң яхшы дәүләт граждан хезмәткәре» республика конкурсы турында нигезләмәдә:

4 пунктта «Конкурс ел саен үткәрелә» сүзләрен «Конкурс кимендә ике елга бер тапкыр үткәрелә» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктның «а» пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Конкурс йомгаклары буенча һәр конкурс төркемендә һәр номинация буенча җиңүче (алга таба – конкурс лауреатлары) билгеләнә, ләкин шул ук вакытта конкурс лауреатларының гомуми саны 14 тән артмаска тиеш.»;

8 пунктның беренче абзацында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы рәсми порталында «Дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәте» бүлегендә (алга таба – Татарстан Республикасы рәсми порталы)» сүзләрен «Татарстан Республикасы рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасының «Дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәте» рәсми сайтында (алга таба – «Дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәте» рәсми сайты)» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Граждан хезмәткәрләре түбәндәге шартлар үтәлгән очракта Конкурста катнаша ала:

а) граждан хезмәтендә:

6 пунктның «а» пунктчасында күрсәтелгән конкурс төркемендә – кимендә ике ел;

6 пунктның «б» пунктчасында күрсәтелгән конкурс төркемендә – кимендә бер ел стажы булу;

б) конкурста катнашуга документлар тапшырган елдан алдагы ел дәвамында дисциплинар җавапка тартылмау;

в) соңгы өч ел эчендә конкурс лауреаты статусы булмау.»;

12 пунктта «Татарстан Республикасы рәсми порталында» сүзләрен «Дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәте» рәсми сайтында» сүзләренә алмаштырырга;

25 пунктта «Татарстан Республикасы рәсми порталында» сүзләрен «Дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәте» рәсми сайтында» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2022 ел, 03 сентябрь
№ ПУ-618